Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



№3
Ноябрь 2017 г.

## В чем секрет дружного класса?

***17-18 ноября в Центре национального образования «Заказанье» прошел районный этап республиканского конкурса «Секреты дружного класса».***

В нем приняли участие самые сплоченные классы Арского района. Вместе с учащимися состязались родители и классные руководители. В этом и заключалась особенность проведения конкурса.

Нашу школу представлял 8 А класс под руководством Рамзили Хабировой. А также родительский комитет: Лилия Рафисовна, Гульнар Ахкямовна, Алмаз Рашатович, Аксана Сергеевна, Айдар Тагирзянович, Гульназ Нафиковна; группа барабанщиц «Ритм»: Адиля Киямова, Аделя Мухаметзянова, Регина Хакимова, Раиля Хабирова; юнармейцы: Адель Гарипов и Даниф Мустафин.

*Продолжение на 2 стр.*



### Интересно знать!

- В среднем в день человек делает **более 18 000 шагов.**
- На протяжении жизни человек съедает **около 27 тонн пищи,** что равняется весу семи слонов.
- На шахматной доске разнообразных **комбинаций больше**, чем в нашей Вселенной атомов.
- Чтобы заснуть, нормальному человеку **требуется в среднем 7 минут.**

## Әниләр көне

***26 нчы ноябрь көнне бар дөнья Әниләр көнен билгеләп үтте. Шул уңайдан безнең мәктәатә дә бик күп чаралар уздырылды.***

Шимбә көнне актлар залында 1В сыйныфы укучылары чыгыш ясады. Класс җитәкчеләре Ралина Сәлахова, зыянайтылган көн төркеме укытучысы Раушания Бакиеваа ярдәме белән бик матур концерт әзерләгәннәр. Матур итеп әниләр турында җырладылар, шигырьләр сөйләделәр. Яраткан әниләренә үз куллары белән ясалган бүләкләрен тапшырдылар.



Соңыннан мәктәп директоры Гөлназ Гиниатуллина бәйрәм уңаеннан әниләргә: «Кдерлеләребез! Мин сезне чын күңелдән әниләр көне белән тәбрик итәм. Сезгә корычтай нык сәламәтек, озын гомер, бәхет-шатлык, балаларыгызның, якын туганнарыгызның игелеген күреп яшәвегезне телим!

- Әни сүзе - иң бөек сүз ул. Әни безне якты дөньяга китерүче, беренче адымнарыбызны ясарга булышучы.» - дип теләкләрен җиткерде.

### В этом выпуске:

| | |
|---|---|
| Җәннәт – аналарның аяк астында | 2 |
| Әниеңә кадер-хөрмәт кыл! | 2 |
| Ана – дөньяда иң бөек кеше | 2 |
| Таулар арасындагы Венеция | 3 |
| Лента новостей | 4 |
| Внимание: конкурс! | 4 |
| Конкурс «Илһамият» | 4 |

...Мы попросили ученицу 8 А Амину Набиуллину рассказать о побольше конкурсе:

- Конкурс - это маленькая победа над собой. Я считаю, что такие конкурсы как "секреты дружного класса" нужны. Они дают возможность проявить себя в чем-то новом и не бояться публики.

Представлять нашу школу нас выбрали не зря. На осеннем балу мы победили в номинации самого дружного класса. Вот с этого всё и началось...

Целую неделю по вечерам мы приходили в школу с родителями на репетиции, советовались с ними, предлагали свои идеи. Поэтому мы заняли III место!

Расспросили их классного руководителя:

**-Как же вы все это успевали? Ведь 1 неделя это так мало для подготовок к конкурсам.**

-Мы оставались после уроков, родители приходили после работы. Наши репетиции длились до 9 вечера.

**-Как же родители и ученики относились к поздним репетициям?**

-Они были очень актины, решали все проблемы. Ученики были заинтересованы. Все сказанное выполняли на совесть. Все большие молодцы!


**-Как вы считаете, нужно ли проводить состязания такого типа?**

-Я думаю, что нужно побольше устраивать похожие конкурсы! Потому что они помогают сблизить детей и родителей.

Хочу выразить свою благодарность нашему директору Гиниятуллиной Гульназ Галиевне, завучу по воспитательной части Лилие Ильясовне Зигангировой, учителю музыки Алине Фердинантовне Мухаметгалиевой, педагогу-организатору Дине Мансуровне Ибрагимовой и всем нашим учителям-предметникам!

*Алия Хабирова, 8Б класс*

# Җәннәт – аналарның аяк астында



*Әниеңә кадер-хөрмәт кыл!*

Һәр кеше үзен дөньяга китергән Әнисен хөрмәт итәргә тиеш. Әти-әниләргә кадер-хөрмәт күрсәтү - балаларның бурычы. Алар балаларга тәрбия бирә, гыйлем бирә, хәвеф-хәтәрдән саклый. Авырсаң шифасын таба. Үсеп җиткәч тә әни өчен бала булып кала.

Шуңа күрә без әти-әниебезгә булыра алганча, кулдан килгән кадәр хөрмәт күрсәтеп, аларга булышырга тиешбез.

Әни сүзеннән чыкмаган, аларның ризалыгын алган кеше җәннәткә эләгергә мөм-кин дип әйтелә. Пәйгамбәребез “Җәннәт аналарның аяк астын-да” – ди. “Әниеңне, әниеңне, әниеңне, аннан соң әтиеңне хөрмәт ит” дигән хәдис тә бар.

*Фаил Кәримов, 8Б сыйныфы*

*Әнисен хөрмәтләгән кеше, оҗмахка керәчәк*

Әни – безгә тормыш биргән кеше. Мин әниемне гаҗәеп яхшылыгы өчен яратам. Өйдә яки мәктәптә мин нәрсә генә эшләсәм дә, ул мине һәрвакыт кичерә, аңлый.

Хәтта начарлык эшләсәм дә: сәбәпсез дәрес калдырсам, акчаны башка нәрсәгә тотып бетерсәм дә, әни мине, әлбәттә, башта ачулана, ә аннан соң барыбер гафу итә. Ул мине нинди генә булсам да – яхшы булсам да, начар булсам да ярата. Еш кына без аларның сүзләренә колак салмыйбыз. Тик соңыннан үкенергә дә туры килә.

Әнием бик матур да минем. Аның күзләре дә матур, чәчләре дә искиткеч хуш исле, куллары да җылы һәм назлы. Авырган чагымда ул кулларын минем маңгайга кую белән, авыруым кими. Үз кулларыма әнинең кулларын алу белән, мин ниндидер изге әйбергә кагылган кебек булам: минем җаным яктырып китә, тормыш аңлаешлы һәм гади булып тоела башлый, борчулар һәм кайгылар онытыла.

*Илназ Дияров, 8Б сыйныфы*

*Ана – дөньяда иң бөек кеше*

Без дәрестә Шәриф Камалның “Буранда” дигән әсәр укыдык. Анда Мостафа исемле кеше турында сүз бара. Ул үзенең әнисен егерме ел күрмәгән, соңлап булса да, аның янына кайтасы килә. Әсәрдә тыштагы буран Мостафаның эчке борчуы белән чагыштырылган. Йокыга киткәч, ул төш күрә: Мостафаны әнисе үз янына чакыра, ләкин анасының аягына ташлангач, ул очсыз-кырыйсыз караңгылыкны гына күрә.

Бөтенебезне дә ана тудырган, яклаган һәм тәрбияләгән. Гомер буе ана үзенең баласы өчен борчылып яши.

Аңламасаң – аңлата, өй эшне ясый алмасаң - булыша. Чыннан да, җир йөзендә анадан да кадерлерәк, якынрак кеше юктыр, мөгаен.



*Алмаз Асадуллин, 8Б сыйныфы*

# Таулар арасындагы Венеция

***Артекка ничек эләккәнемне, бәлки, гәҗитебезнең 2нче санында укып белгәнсеңдер. Ниһаять, лагерьда уздырган иң бәхетле өч атнам турында да сөйләргә вакыт җитте, дустым.***

Планетабызның яшеллеген саклауга багышланган III Халыкара яшүсмерләр медиафорумына яшь журналистлар һәм география белгечләре җыйналды.

17 нче октябрь. Кичке сәгать җиде. Без Симферополь шәһәрендә. Татарстаннан килгән биш кыз һәм ике егет (алар арасында мин дә бар) “Артек” дип язылган зур автобуста төнге икенче яртыда Артекка килеп җиттек. Безгә “Диңгезкәй” лагеренда яшәячәгебезне әйттеләр. Бу минутта үземне дөньяда иң бәхетле кеше итеп хис иттем. Тиз генә бүлмәләргә урнашып, иртән безне нилэр көтәсен уйлый-уйлый, татлы хыяллар белән йокыга талдык.

Ниһаять, таң атты! Уянуга, тәрәзәгә күз салдым. Иксезчиксез диңгез, уйнаклап йөгерешкән дулкыннар мине әсир итте. Бу көн танышып, төрле уеннар уйнап, кызыклы вакыйгалар тыңлап үтте дә китте.

1982 нче елда Америкада яшәүче 11 яшьлек Саманта Смит сугыш башланудан курсып, Юрий Андроповка хат юллый. Анда ул: “...я хотела бы знать, почему Вы хотите завоевать весь мир или, по крайней мере, нашу страну? Бог создал Землю, чтобы мы все вместе жили в мире и не воевали,” - ди. Бернichә айдан Андроповтан Артекка юллама белән бергә җавап хаты килә.

1983 нче елның җәендә кыз эти-әниләре белән Артекка ял итәргә килә. Инглиз телен белмәүчеләр дә аның белән очрашыр өчен чиратта тора.

Лагерьда Саманта үзенә иптәшләр таба, СССРда бары тик дуслык кына хөкем сөргәнен аңлый.

Ике елдан ул әтисе белән авиахаләкәткә эләгеп, бакыйлыкка күчә. 1985нче елда Артекта Саманта Смитка багышланган һәйкәл ачыла. Шуннан бирле лагерь чит ил балаларын да үзенә кабул итә башлый.

Кичен безне әйдаманнар әзерләгән зур тамаша көтә иде. Юкка дулкынланмаган икән яраткан тәрбиячеләребез. Аларның нилэр майтарганын күреп таң калдык. Профессиональ циркачлар, биючеләр диярсең үзләрен. Бу искиткеч могҗизаны ике төн эчендә генә әзерләгәннәр димәссең! Һәрберебез аларга ихтирам, хөрмәт белән карый башладык. Миндә дә әйдаман булу теләге туды.





Артек булгач, мәктәп тә, укулар да юк дип уйлыйсыңдыр. Бар да, юк та. Аның урынына монда чын Хогвартс! Ышанмаслык бит, әйеме?! Без үзебезне чын Гарри Потер итеп хис иттек. Смена барышында мәктәптә биш кенә тапкыр булсак та, көннәрне заяга уздырмадык. Дәресләр төрле музейларда, саф һавада алып барылды. Уку азагында безгә өлгереш табельләре тапшырылды әле.

Өйдә булсам, алтынчы яртыда гомердә йокыдан тормас идем. Ә монда?.. Йоклап калмагаем дип яттым.

*Дәвамы 4 биттә...*

Чөнки безне Севастополь шәһәренә сәяхәт көтә. Андагы музейлар, хан сарайлары шаккатмалы. Иң ошаган урын Балаклава булды. Таулар арасына сыенып утырган култык миңа Венецияне хәтерләтте. Елга буенда яхта, төрле зурлыктагы көймә, кораблар, ә су төбендә медузалар, төрле төстәге балыклар күзне камаштыра.

Бер карасаң, 21 көн озак кебек. Ә без аны сизми дә калдык. Шәп ял булды бу!

Рәхмәт Артекка безне үз иткәне өчен! Сайлап алу этабында ярдәм иткән укытучыларыма, әти-әниемә рәхмәт.


Ә син дустым, монда эләгәсең килсә, тик утырма! Бәйгеләрдә катнаш, җиңүләр яула! Барысы да синең кулда!

*Рүзәл Шәрипов,*
*8Б сыйныфы*

# Лента новостей

### *Внимание: конкурс!*

9 декабря – День Героев Отечества. В связи с этим отдел военного комиссариата РТ по Арскому и Атнинскому районам совместно с редакцией газеты «Арский вестник» объявляют конкурс сочинений для обучающихся 5–11 классов.




Сочинения нужно отправить по почте arvestnik@yandex.ru с пометкой «в конкурс «Герои». Последний день приема конкурсных работ 7 декабря. Итоги будут подведены 8 декабря. Победителей ждут призы.

### *Наши призеры*

13 ноября начались районные этапы предметных олимпиад. В них приняли участие и стали призерами следующие обучающиеся нашей школы.

***Английский язык:***
Айгуль Мухамматгалиева, 11В
Нияз Зиннатуллин, 5А
Гузелия Фаттахова, 4Б

***Искусство:***
Айсылу Шамсутдинова, 11Б

***Русский язык:***
Ралия Низамова, 6Б

***Экология:***
Эмиль Гараев, 7Б

***География:***
Азамат Валишин, 7А

***История:***
Рузиля Нигмадзянова, 10 кл.

***Математика:***
Данияр Гибадуллин, 4А
Манаков Арсений, 6Б
Степанов Данил, 8Б
Залялиева Гульфина, 10 кл.

*Поздравляем!*

### Победители конкурса «Илһамият»

25 ноября в городе Казани прошел Международный фестиваль-конкурс речевого и вокального искусства «Илһамият», в котором приняли участие и наши ученики.



Розалия Габдерахманова (подтанцовка Аида Мингазова и Лейсан Залаева) стала лауреатом I степени, Нияз Асадуллин - дипломант III степени, вокальный дуэт «РозалИс» - лауреат I степени!

Поздравляем и желаем дальнейших творческих успехов!

### День памяти жертв ДТП

14 ноября в школе прошло мероприятие посвящённое Всемирному Дню памяти жертв ДТП на котором, запустив в небо воздушные шары, почтили память погибших при авариях. На мероприятии присутствовала начальник отделения профилактики по Арскому району ГБУ Безопасность дорожного движения Мухаметзянова Эндже Газизовна.

### Служим Отечеству...

23 ноября отряд «ФОРПОСТ АСОШ №2», принял участие в Республиканском семинаре школьных отрядов правопорядка "Служим Отечеству, служим народу» Республики Татарстан г. Казань.



### Чемпионат КВН

23 ноября прошёл чемпионат КВН Арского района РТ. Команда нашей школы одержала победу в номинации «Лучшая шутка». Молодцы!

**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Ответственный секретарь*** Рузаль Шарипов
***Редколлегия*** Алия Хабирова
Фаиль Каримов
Ляйсан Шаяхметова
Алмаз Асадуллин
Диана Галимова
***Адрес*** ул. Мостовая 15
***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2

